РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.07.2022 — № 642-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 2 декабрендәге 1375-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 2 декабрендәге 1375-п номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– түбәндәге юлдан соң таблицада:

«

| | | |
|---|---|---|
| 380 | 1 11 07015 05 0000 120 | Саба муниципаль районы төзегән муниципаль унитар предприятиеләрнең салымнар түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләреннән соң калган табыш өлешен күчерүдән керемнәр |

»

түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 380 | 1 11 09045 05 0000 120 | Муниципаль районнар милкендәге мөлкәттән (муниципаль автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре, мөлкәтеннән тыш) файдаланудан башка керемнәр |

».

Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 23 сентябреннән барлыкка

килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru. рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов